УДК 821.512

***Э.М. Галимҗанова,***
***Г.А. Хөснетдинова***

# ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ЭПИСТОЛЯР МИРАСЫ

Выдающийся татарский писатель Фатих Амирхан внес значительный вклад в развитие татарской литературы и культуры. Интерес к его личности и творчеству сохраняется и в настоящее время. В связи со 140-летием со дня рождения писателя сотрудниками Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ была подготовлено и издано шеститомное академическое издание сочинений Фатиха Амирхана.

Шестой том издания содержит 118 писем, которые в настоящее время хранятся в Центре письменного наследия Института. Письма, датированные 1902–1925 гг., разделены на две части: «Письма Фатиха Амирхана» (61 письмо) и «Письма к Фатиху Амирхану» (57 писем). Среди писем, адресованных Ф. Амирхану, представлены письма таких видных деятелей татарской литературы, как Габдулла Тукай и Гаяз Исхаки, а также его современников.

Особую ценность представляет переписка Фатиха Амирхана с педагогом, учителем, писателем, журналистом и историком Ризваном Алуши (1883–1938). Она позволяют глубже понять душевное состояние писателя и расширить представление о его творчестве. Ф. Амирхан также поддерживал дружеские отношения с женой Ризвана Алуши, Фарханой (Бахетгузиной, 1886–1958). Фархана была одной из образованных женщин своего времени, долгое время работала учительницей в сибирских школах, до революции писала статьи о женском образовании и освобождении татарских женщин.

Из 32 писем, адресованных Ризвану Алуши, 4 написаны обоим супругам, 2 письма адресованы исключительно Фархане. Среди писем от Ризвана и Фарханы, сохранились 4 письма Ризвана и 2 письма Фарханы. Представленные письма датированы 1908 и 1910 годами.

В письмах раскрываются личные аспекты жизни писателя, семейные отношения, любовь, горесть утраты, связанные со смертью сестры Фарханы Рахимы.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, Ризван Алуши, Фархана Алуши, татарская литература, текстология, источниковедение, письма

The prominent Tatar writer Fatih Amirkhan made a significant contribution to the development of Tatar literature and culture. Interest in his personality and work continues today. In honor of the 140th anniversary of his birth, the staff of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature, and Art of the Tatarstan Academy of Sciences prepared and published a six-volume academic edition of Fatih Amirkhan's works.

The sixth volume contains 118 letters, which are currently housed in the Institute's Written Heritage Center. The letters, dated 1902–1925, are divided into two parts: "Letters of Fatih Amirkhan" (61 letters) and "Letters to Fatih Amirkhan" (57 letters). Among the letters addressed to F. Amirkhan are those of such prominent figures in Tatar literature as Gabdulla Tukay and Gayaz Iskhaki, as well as his contemporaries.

Of particular value is Fatih Amirkhan's correspondence with the educator, teacher, writer, journalist, and historian Rizvan Alushi (1883–1938). It provides a deeper understanding of the writer's state of mind and a broader understanding of his work. F. Amirkhan also maintained a friendly relationship with Rizvan Alushi's wife, Farhana (Bakhetguzina, 1886–1958). Farhana was one of the most educated women of her time, having worked for a long time as a teacher in Siberian schools and before the revolution, writing articles on female education and the liberation of Tatar women.

Of the 32 letters addressed to Rizvan Alushi, four were written to both spouses, and two letters were addressed exclusively to Farhana. Among the letters from Rizvan and Farhana, four letters from Rizvan and two from Farhana have survived. The letters presented are dated 1908 and 1910.

The letters reveal personal aspects of the writer's life, family relationships, love, and the grief associated with the death of Farhana's sister, Rahima.

**Keywords:** Fatih Amirkhan, Rizvan Alushi, Farhana Alushi, Tatar literature, textual criticism, source studies, letters

Татар халкының сөекле улы Фатих Әмирхан – татар әдәбияты тарихы, мәдәнияте үсешенә зур өлеш кертkән әдип. Аның иҗаты гына түгел, шәхесе дә хәзерге көндә җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята.

Күптән түгел әдипнең 140 еллык юбилее уңаеннан ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән Фатих Әмирхан «Әсәрләр»енең алты томлы академик басмасы дөнья күрде. Әлеге басманың 6 нчы томына 118 хат урнаштырылды. 1902–1925 елларда язылган әлеге хатлар бүгенге көндә Институтның Язма мирас үзәгендә саклана. Томда хатлар «Фатих Әмирхан хатлары» (61 хат) һәм «Фатих Әмирханга язылган хатлар» (57 хат) дигән ике өлешкә бүленеп тәкъдим ителде.

Ф. Әмирханга язылган хатлар арасында Габдула Тукай, Гаяз Исхакый кебек күренекле язучыларыбызның хатлары белән беррәттән, Ф. Әмирхан даирәсендә кайнаган замандашларының хатлары да бар. Фатих Әмирханның якын дусты, педагог, мөгаллим язучы, журналист һәм тарихчы Ризван Алуши (1883–1938) белән алышкан хатлар аерым кыйммәткә ия. Алар язучының күңел халәтен ачыкларга, иҗатын тагы да киңрәк ачарга ярдәм итәләр.

Ф Әмирхан Р. Алушиның хатыны Фәрханә (1886–1958) белән дә якын дустанә мөнәсәбәтләрдә булган. Ризванга юлланган 32 хатның 4 се – икесенә дә, 2 хат Фәрханәгә язылган. Ф. Әмирханга язылган хатлар арасында Р. Алушиның – 4, Фәрханәнең 2 хаты бар.

1908, 1910 елларда язылган әлеге хатларның күбесе – Фәрханә Алуши белән алышкан хатлар. 1908 елда язышкан хатларда Шәмсениса Камаловага (әтисенең энесе – Чистай мулласы Нәҗип Әмирхановның балдызы, 1886–1930) гашыйк булуы турында бәян ителсә, 1910 елгы хатларда Фәрханәнең Ачинск гимназиясендә укучы сеңелесе Рәхимәнең (Бәхетгузина, 1893–1910) вакытсыз үлеме хакында сүз бара.

Тәкъдим ителгән хатлар әдипнең шәхси тормышын, иҗатын тулырак күзалларга ярдәм итәләр. Алар кара-каршы хат язышу тәртибендә бирелә.

## 1. ФАТИХ ӘМИРХАННАН ФӘРХАНӘ АЛУШИГА

*1908 ел, 15 сентябрь, Казан*

Әлхатты ныйсфел-мөлякат[1].

Сиңа газизел-вөҗүд[2] вә кәсирел-сөҗүд[3] улып торучы сеңелемез Фәрханәҗамалга бик чуктан-чук сәламнәремне күндерәм. Үземездән хәл-әхвәл истифсар улынса[4], әлхәмде лилләһи раббил-галәмин әр-рахмәннир-рәхим, мәлики йәүмиддин. Ийәкә нәгъбүдүүә ийәкә нәстәгыйн. Вә ләд-далин, амин[5], сау-сәламәт торамыз. Мин бәгъдә әмре фикерендән вә бәгъдә[6] җибәргән саннарны алганлыкны белеп бик шат булдык. Ачып караган муллага хуҗа Баһаветдиннең ләгънәтләре төшсен. Әле укыта башламыйча лодырничать итәсең икән, Ходай тәүфыйк, һидаять[7] биреп, җөмләмезне[8] ислам юлыннан аермасын. Амин! Уразада аш хәзерләргә торуың өчен, җәһәннәмдә януыңны бер дә уйламыйсыңмыни? Валлаһи газыйм, бу эш ярамый.

Хәләл җефетең Ризванетдинның язуына караганда, син Казан хатыннарыча киенеп, башка төенчек куеп йөрергә уйлыйсың икән. Ходай сау-сәламәтлек белән башланган эшеңне очлап чыгарга насыйп итсен. Казанда нинди яңа хәбәрләр дисеңме? Менә мин монда теге Ш. туташ Камаловага (Серноводскидагы) гашыйк булдым дип исем чыгардым. Яшьләрнең һәммәсе шуны мөзакәрә[9] мәшгульләр. Ник гаҗәпләнәсең? Гыйшык – Йосыф пәйгамбәрдән калган сөннәт ул[10]! Синең монда участвовать итүеңне бик яратып калганнар, һәммәсе яхшы уйнады дип сөйлиләр. Хәзергә хуш, сеңелкәем!

Озакламый тәпи йөри башлаячак агаң Фатих.

## 2. ФӘРХАНӘ АЛУШИДАН ФАТИХ ӘМИРХАНГА

*[1908]*

Һөвә

Фатих абзый! Фатих (әфәнде) абзый!

Хатыңны алып укыдым, язганыңа рәхмәт.

---

[1] Әлхатты ныйсфел-мөлякат – хат – кавышу, очрашуның яртысы.
[2] Газизел-вөҗүд – исән булган газиз.
[3] Кәсирел-сөҗүд – зур табындыгыбыз.
[4] Истифсар улынса – соралса.
[5] Коръәннең «Фатиха» сүрәсенең баштагы һәм ахыргы юллары.
[6] Бәгъдә – соңрак.
[7] Һидаять – туры юлга керү теләге.
[8] Җөмләмезне – барчабызны.
[9] Мөзакәрә – сөйләү.
[10] Сөннәт ул – тиеш эш ул.

Казанда Камаловага гашыйк булдым дию хәбәрен чыгаргансың икән, ул була торган эш – пәйгамбәрләрдән калган. Шулай юри генә сөйләнгән сүзләрнең соңында хакыйкать булып киткәннәре дә юк дәгел. Чын булса да, егет кешегә гаеп түгел, яшь чакта бар да була.

София, Әминәләр киткәннәр икән. Рабигалар илә йөрешмисез бугай. Сиңа ухаживать итәргә кеше дә калмаган. Ә мин үз тарафымнан Шәмсекамәрне [1] предлагать итәм, күңел юатыр өчен забавга[2] баласы да бар бугай.

Нихәл, тансовайт итә башладыңмы инде?

Без яхшы торамыз. Синең тәтиле тәбригеңне алдык.

Гаедем бик аның аркасында мөбарәк узды, хәтта постелемнән тора алмый агырап яттым.

Көннәремез яхшы үтә, ләкин Казанны да сагынамыз. Бик-бик кызык кына хат яз.

Аллам, Алла дигәндә ...

Без кыз егетләр, егетләр дигәндә ...

Вәссәлам

Фатыймага, Фәйрүзәгә миннән сәлам әйт. Синнән хат алгач, озынны язармын.

Сеңелеңез Фәрханә ханым.

## 3. ФАТИХ ӘМИРХАННАН РИЗВАН ҺӘМ ФӘРХАНӘ АЛУШИЛАРГА

*1908 ел, 2 декабрь, Казан*

Газизем Ризван!

Сиңа хат язарга уйлый башлаганыма бик күптән. Менә бу көн билфигыль[3] эшкә тотындым – язам. Синең җибәргән рисаләчегеңне алдым. Ләкин язылуы фәлсәфә сату тарикынча булганлыктан һәм дә күп урыннарда кызып китеп ифратларга төшкәнлектән, ошатмадым. Мәсәлән, татар газеталарында төрле, дөрестлеге шөбһәле хәбәрләр дәреҗ ителүне син мөхәррирләрнең русча белмәвенә һәм мәдрәсә җимешләре булуына сылтыйсың. Гаспринский, Шахтәхтинский[4] (әүвәлге «Казан мөхбире» вә «Таң») һәяте тәхририясен[5] болай гаепләвең никадәр вөҗүдсез[6] икәнен кем белми, икенчедән, рисаләдә бер әсаси нокта[7] булмаганлыктан, бер-берсенә каршы тора торган фикерләргә

[1] Хатта искә алынган Шәмсекамәр (1880–1936) – Гафур Коләхмәтовның бертуган апасы, Габделхәмит Апанаевка кияүгә чыгып, озак тормый аннан аерыла, бу никахтан аның Гайшә исемле кызы туа: булачак язучы, тәрҗемәче Гайшә Габделхәмит кызы Шәрипова (1901–1969).

[2] Забавга – забава дигән рус сүзеннән (күңел ачарга).

[3] Билфигыль – чынлыкта.

[4] Азәрбайҗан журналисты һәм җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәд Солтан улы Шахтәхтинский (1846–1931). Тифлиста 1903–1904 елларда чыккан «Шәркы рус» («Россия Көнчыгышы») газетасының мөхәррире.

[5] Һәяте тәхририясен – басмаларын.

[6] Вөҗүдсез – нигезсез.

[7] Әсаси нокта – нигез.

бина кылынып вә һәммәсен бер катарга[1] кертеп язылган нәрсәләргә дә тугры киленә. Шуңар күрә аның төгәл синең исем астында, бәлки гомумән бер дә исемсез генә дә матбугат галәменә чыгуын муафикъ күрмим.

Казан хәбәрләренә килсәк, алар бер килеш баралар. «Әлислах» акрын гына эленеп-салынып кына бара. Хәзер форматын үзгәртеп, мәсләген[2] дә сәясиләндерергә карар бирдек, бәлки аннан соң тәртипле бара башлар. Казан яшьләренең күбрәге мөшарәкәт итәргә вәгъдә биреп торалар.

Казанда хәзер һәр атнада спектакль вә әдәбият кичәләре булып торалар. Көннәр кызыграк узалар, аяклар минем ярыйсы ук булып киләләр. Йөри башлагач, аягүрә төшкән рәсемемнең әүвәлге данәсен сезгә җибәрермен.

Бу ел Казан яшьләре тырышрак күренәләр, һәммәсе укый, эшли, илүмән кымкырыч[3] килеп бетәләр. Укый торгансың, мин хәзер «Әлислах»та замана хикәяләре яза башладым. Син шулар хакында ни фикердә?

Мин октябрь башыннан бирле чынлап тотынып укырга керештем. Аяксызлык файдасы буларак, күп нәрсә укырга да өлгерәм. Әгәр җәй көне берәр суга барып вакыт уздырмасам, көзгә 6 класстан имтиханга керергә уйлыйм.

Хат яз!

Калган хәбәрләрне Фәрханәдән сораш, аңар язам.

Фатих.

Теге яктагы хатны үзең укымыйча гына Фәрханәгә бир.

Фәрханә!

Син исәнме, саумы? Зур абыстай булып киләмсең инде? Агаң хәзер зур үсеп килә инде. Ихтимал, тиздән тәпи дә йөри башлар. Синең матур гына бер сеңелең дә бар иде. Ул нишли, аннан хәбәрең бармы? Кара әле, син аны миңа димләштерә башлап куйсаң ярар иде.

Ә, әле оныта язганмын: син миңа Шәмсекамәргә гашыйк булырга кушкансың, аның өчен мин сиңа протест биреп, күп каһәрләр укыйм!!!

Мин инде бер кат Ш. туташ Камалованы сөйгән, ә син шунда үзеңнең әллә нинди Шәмсекамәрләрең белән лезать итәсең. Ризванга әләкләп кыйнатыйм да дип бер уйлаган идем дә, хәзергә торып торсын инде, дидем.

Минем коляскага утырып, Серноводски урманына барганыбызны хәтергә китерәмсең? Пенснеңә[4] кыстырган утын кисәге төшеп калганы юкмы әле?

---

[1] Катарга – рәткә.

[2] Мәсләген – тоткан идея юнәлешен.

[3] Илүмән кымкырыч – үзара мәш килеп.

[4] Сүз кириллицада бирелгән.

## 4. РИЗВАН АЛУШИДАН ФАТИХ ӘМИРХАНГА

*1910 ел, 29 март*

Һөвә

Фатих әфәнде!

Без һаман сыхранудан, күңел болгаткыч хәбәрләр язудан тыела алмыйбыз. Бу эш безгә табигать булып урнашыр ахры инде. Затән сыхрамаслык да түгел, ике ел кадәр табигатьнең һөҗүменә грифтар булып[1], син авырып яттың. Ярый әле үзеңне алып кала белдең. Шуның илә безне шатландырдың. Юк исә, бирелеп куйган булсаң, бөтен өмид вә максудларымыз вөҗүдкә чыкмай[2] бергә бетә иде. Ул вакыт син әле танылмаган улдыкыңнан тәмам онытылып дусларның калебендә[3] генә калган булыр идең. Ә хәзер! Ә хәзер син мәңгегә бар. Бу җөмләләремә күңелсезләнмә. Бер үземнең хиссиятемне генә бәян, түбәндә язылачак кызганыч кан агарлык күңелсез хәбәремә мөкаддәмә[4] генәдер. (Ягъни үләргә тели икән димә!) Без үземезнең теләк вә максудларымызны сөеклемез Рәхимә туташка тапшырган идек. Безнең бар өмидемез шул иде. Ул үзенең иҗтиһады[5] вә татар кызларында мисле[6] күренмәгән истигъдады[7] вә хөсне әхлакы илә безне үзенә мөсәххәр иткән[8] иде. Без аннан башка тора алмаслык дәрәҗәгә килгән идек. Анардан бер җәмигъ хат килмәсә, тәмам кайгыга салына идек. Менә инде хәзер анардан мәңгегә аерылдык, мәңгегә хәбәрен ишетмәскә ителдек. Чөнки ул хәзер вафат, ул безнең һәм үзенең бар өмид вә максудларыны, үзе илә бергә алып китте. Безне вә ата-анасын мәңгегә еглатып калдырды һәм вакыйган мәрхүмә егламаслык да түгел. Ул бит бөтен Себергә бер өмидле татар кызы иде. Ләкин татар милләте андай кояшлардан мәхрүм, татар галәме анларны шулай күрә алмас ахры инде. Аның вафаты безнең өй эченең нуры, хозуры китүгә дә сәбәп булды. Хәзер Фәрханәне юатудан гаҗиз улып[9] торамыз.

Мөхтәрәм Фатих әфәнде «Яшьләр» наме рисаләңне алдык. Сөенә-сөенә тәкрар укыдык һәм һаман килгән-киткән бер кешегә укыймыз. Менә ул тормышка ашна[10] күбесен күреп белдегемнән, бигрәк сезнең үз җизнәгезнең тәмәсселе мөҗәссәме булуы[11] хиссиятеннән бигрәк ярattык. Укыганда һәрберсен көннәре илә искә төшерәм.

---

[1] Грифтар булып – дучар булып.
[2] Вөҗүдкә чыкмай – тормышка ашмый.
[3] Калебендә – йөрәгендә, күңелендә.
[4] Мөкаддәмә – кереш.
[5] Иҗтиһады – тырышлыгы.
[6] Мисле – кебек, төсле.
[7] Истигъдады – сәләтлелеге.
[8] Мөсәххәр иткән – әсир иткән, сихерләгән.
[9] Гаҗиз улып – көчсез, зәгыйфь булып.
[10] Ашна – таныш.
[11] Тәмәсселе мөҗәссәме булуы – прототибы булуы.

Вә шундай бер ядкәр язуың өчен аеруча рәхмәтләр укыйм. Үз арамыздан шунларны тасдыйк итәрлек[1] кеше заһир итүенә[2] шатланам.

«Ялт-йолт» игъланында сезнең дә исем күренә һәм башка язучылар да безнең каршыда оста саналдыкыннан яхшы булып чыгуына өмидемез куюдыр. Фәкать «Карчыга», «Чүкеч», «Яшен», «Әлислах» кеби бер мөштәриләренә[3] тиешенчә бирелмәй калдыкларыннан алучыларның рәгъбәт[4] вә ышанычлары аз улу ихтималы да бар. Шулай да халык андый бер журналга мохтаҗ улдыкыннан шаяд муаффәкыятьле[5] улыр.

Бездә артык мөһим әхвәлләр юк, сәүдәне шулай бер көе итеп торамыз. Шундай кайгылы вә тынычсыз вакытымызда берәр мәктүбтән шаяд[6] мәхрүм итмәссез.

Бакый сагынып сәлам. Ризван. 1910 нчы сәнә, март 29.

Да, шуны да язасы бар икән. «Ялт-йолт»ны «Яшен» кеби Казан тирәсендә генә ялт-йолт иттермәй, гомумирәк ясарга тырышыгыз.

## 5. ФӘРХАНӘ АЛУШИДАН ФАТИХ ӘМИРХАНГА

*[1910 ел, март-апрель]*

Мөхтәрәм Фатих әфәнде!

Мин сиңа «Татар кызы» рисаләңне алганнан бирле хат язарга җыенам, ләкин һаман бушый алмыйм. Мин ул рисаләңне укыгач, татар кызларын дүрт стена эченнән якты галәмгә чыгарырга тырышучы бердәнбер муаффәкыятьле герой, «татар егете» дию сине атый башладым. Шуны алгач да, Ачинскига киттем. Ул рисаләне татар кызларының ул тормышын күрмәгән сөекле сеңелем, өмид кояшым Рәхимәгә бирдем. Укыды, «җанлы курчак», «кара көч» кеби гыйбарәләре күңеленә ятлап алды. Аны язган өчен калебенең иң нечкә җиреннән сиңа рәхмәтләр укып, сәламен ирештерергә кушты. Мин һаман бу көнгә кадәр кичектердем, яза алмадым, гафу боерасыз. Имди язам, ләкин ул фәрештә, ул бәгърем туфрак астында, ул хәзер башка галәмдә, ул безне ташлады, мәңгегә калебемезне җәрәхәтләде. Хәятта интересым калмады, мин аның өчен генә яши идем. Үземез ирешә алмаган дәрәҗәләргә аны ирештерү касдында идем. Бөтен көчемне шуңар сарыф итә идем. Ул без көткәннән артык булып бара иде. Менә дүртенче класска иреште. Бер ел калмады, һәр заман бишен алып, иптәшләре арасында беренче булып килде. Ул аның илә генә калмый. Татар галәме илә дә таныш иде. Бар теләк вә максуды татар кызларын яктылыкка чыгару иде. Аның өмид вә максудларын мин сиңа язып бетерә алмыйм. Мин фәкать үземнең аннан соң яши

---

[1] Тасдыйк идәрлек – расларлык.
[2] Заһир итүенә – билгеле булуына.
[3] Мөштәриләренә – яздырып алучыларына.
[4] Рәгъбәт – теләк.
[5] Муаффәкыятьле – уңышлы.
[6] Шаяд – бәлки.

алмаячагымны, бөтен интересым бетдекене генә язам. Фатих, менә икенче җомга улды, мин һаман айный алмыйм, еглыйм, кан еглыйм, йөрәгем парә-парә улып бетте. Бөтен жизнемнең яме югалды. Мин аның рәсеменә карый алмыйм, хатларын укый алмыйм. Аның соңгы хатын сиңа язсам, күпме каты күңелле булсаң да, эреп китәр идең, инде мин нишлим. Миңа ни илә юанырга кушамсың, минем хәзер ихтыярым үземдә түгел. Мине фәкать бер такым[1] дини куркытулар илә генә саклыйлар.

Менә, кара, мин сиңа иң соң алдырган рәсемен җибәрәм.

Мин аңар табынам. Фатих, нидән бу кадәр несчастье, неужели шундый вакытсыз үлем бар, минем бер тутам ике елдан бирле өмидсез авыру берлән аурады. Менә хәзер сәламәтләнгән дию ишетәм. Ә бу 13 гыйнварда юри гына башым авырта дию яткан йиреннән 17 мартта үлде. Һәр көн иртә берлән, хәлем яхшырак дию, гимназиягә барырга хәзерләнә икән. Бу нидән, Алладанмы бу золым, фәләктәнме[2]? Мин аптыраган. Минем күзләрем яшь, йөрәгемә кан урнашкан, кулым калтырый, артык яза алмыйм. Фәкать синнән берәр нәрсә илә күңелемне юатуыңны теләп сүземне тәмам итәм. Фәрханә.

## 6. ФАТИХ ӘМИРХАННАН ФӘРХАНӘ АЛУШИГА

*1910 ел, 11 апрель, Казан*

Газизәм Фәрханә!

Синең хатыңны кичә алдым, ни әйтим, ул кара хәбәр китергән хат, бер дә көтелмәгән... (тәгъбир хатарак[3]) бер дә көтәргә теләнмәгән хат, мине дә синең настроениеңә төшерде. Болай да жизньнең һәр ягында кара таплар гына эзләп тора торган минем рухыма бик авыр тәэсир итте. Бик җөрьәтле әйтә алам ки, әгәр дөньяның, хәятның кара бүләкләре мине егларга мәҗбүр итә ала торган булсалар иде, мин бу хат китергән хәбәргә дә еглар идем, сабый бала шикелле еглар идем. Вакыйгага баштан тотыныйм: мин хәзер бер татар газетасын да кулыма тотып карамыйм, шуңар күрә аларда чыккан хәбәрләрне дә иптәшләремнән генә ишетеп ярым-йорты гына беләм. Моннан ун көннәр әүвәл булырга тиеш, иптәшләремнән берсе, миңа килеп, башка сүзләр арасында киләчәктәге сүзләрне сөйләде:

– Понимаешь, хәзер Себер муллалары арасында кызларын гимназияләргә биреп укытучылар була башлаган икән. «Вакыт»та әле шундый бер гимназистканың үлеме хакында атасы язган... Удивительно[4], татар арасында кем үлә дисәң, укучы халык үлә, нинди кара бәхет татарны каплаган, ә?

Бу хәбәр минем йөрәккә бер генә мәртәбә үткен пәке белән сызылган шикелле ачы хис бирде дә, мин артык уйлап тормыйча:

[1] Такым – төркем.

[2] Фәләктәнме – язмыш, тәкъдирдәнме.

[3] Тәгъбир хатарак – термин, сүз ялгышрак.

[4] Сүз кириллицада бирелгән.

– Камәр («Кәләпүшче кыз» хикәясенең героинясы) Камәрләрен чыгарырга тиеш, шуңар мәхкүм[1] бер милләттә хакыйкатән дә гимназисткаларга урын юк, алар үләргә тиешләр, бетәргә тиешләр, алар «Камәрләр» була алмыйлар, шуңар күрә татаркалар да булмасыннар, – дидем. Бу хактагы сүз шуның белән бетте. Менә никадәр вакытлар узгач, синең хатың килә... Рәхимә үлгән!

Әнә шул карточкадагы яшь, саф, өмид белән ялкынлана торган Рәхимә үлгән... Рәхимәнең күзләренә карыйм, ул гакыллы күзләр миңа аның үлгәнлегенә ышанмаска кушалар төсле тоела. Минем әллә кемне бик нык сүгәсем килә, Рәхимәне үтергән нәрсәгә Яңа бистәнең берәүгә дә кирәкмәгән Сәхип карчыкларын тотып китереп: «Син яңлыш эшлисең, син әллә гакылдан шаштыңмы? Бу бит татар арасындагы иң кадерле, иң аз очрый торган чәчәкләрнең берсе, калдыр аны!» – дип кычкырасым килә...

Аннан соң үз-үземнән көләргә тотынам, имеш тә, Фатих терек икән дә, Рәхимә үлгән икән! Имеш, Фатих үзе терек булганга күрә, Рәхимәне үлде дип кызгана икән! Глупо, кем бәхетлерәктер бит? Кем кемне кызганырга тиештер бит? Авось, Рәхимә Фатихны кызганырга тиештер. Имеш тә, Ризваннар, Фәрханәләр, Фатихлар һәммәсе үлмәгәннәр икән. Имеш тә, алар ашап-эчеп, йоклап, капиталга табынып, бер-берсенә табынышып, үз хыяллары белән ясап чыгарганнарны – глупость[2]ларны бәхетлелек санап йөриләр икән дә, Рәхимәне шул нәрсәләргә мөдахәлә итмәгәнлеге[3] өчен кызганалар икән. Глупо! Очень даже![4]

Имеш тә, Фәрханә, Ризван, Фатих хәзер чәчләре агара башлаганлыгын, тешләре җимерелә башлаганлыгын көтеп, үзләренең маймыл кыяфәтендә кеше булып калганнарын көтеп, скучать итеп яталар икән дә, шул страдание[5]ләренең берсен дә күрмичә, вечный покойга киткән иптәшләрен кызганалар, имеш!

Имеш тә, Фатих үз-үзен алдап, үзен мөхәррир санап, Фәрханә белән Ризван сату иттереп, шуны кирәккә санап яталар икән дә, үз-үзен алдарга өлгермәгән, шул мөхәррирлек, сатучылык, милләтчелек, инсаниятчелек дигән шакшыларга буялмый үлгән Рәхимәне кызганалар икән! Тотыңыз капчыгыңызны! Фатихлар, Фәрханәләр, Ризваннар, тагын әллә кемнәр: шайтаннар – менә кызганыч бәндәләр! Ә Рәхимәме? Фәрештә булганга тәнзил итмичә[6], без күрми торган җиргә очкан, дим. Менә болар – минем бер-берсе артыннан килгән ике настроением. Мин үзем соңгысына күбрәк ышанам: син, газизәм, теләсәң нишлә!

---

[1] Мәхкүм – хөкем ителгән.
[2] Сүз кириллицада бирелгән.
[3] Мөдахәлә итмәгәнлеге – катышмаганлыгы.
[4] Сүзләр кириллицада бирелгән.
[5] Сүз кириллицада бирелгән.
[6] Тәнзил итмичә – түбән төшмичә.

Сиңа ирешкән бу кайгының хәяттагы кайгылар арасында бик зуры икәнен мин яхшы аңлыйм, ләкин әле синең бик исең китеп, зур бәхет санап йөри торганың хәяттагы кешеләргә мондый кайгылар каршында сәҗдә итәргә ярамый: бу бик йомшаклык, бик гайрәтсезлек, бик жизньне аңламаганлык була. Безме, без: без дөнья җимерелсә, бөтен адәм баласы һәлак булса, шулар белән бергә үземез дә һәлак булсак, анда да тавышымызны чыгармый, мәлгунь тормышка сер бирмәс өчен, аһ да итми һәлак булырга тиешләрмез. Шулай, газизәм, моннан соң күзеңнән бер катрә[1] дә яшь чыгара күрмә: еглаган, булган хиссиятеңне юган, артыгы – лишний. Ә Рәхимә соң дисеңме? Ул хәзер үлеп яхшы иткән, чөнки кайчан да булса бер үләр иде. Ләкин безнең барымыз шикелле тормыш нәҗесләренә буялып үләр иде. Ә хәзер фәрештә көе үлгән – ул бәхетле.

Дустың Фатих.

Миңа кайчан да булса «Татар кызы» шикеллерәк берәр нәрсә язарга (туры килсә), мин аны шул бәхетле туташка посвящать итәчәкмен.

## 7. ФАТИХ ӘМИРХАННАН РИЗВАН АЛУШИГА

*1910 ел, 11 апрель, Казан.*

Газизем Ризван!

Миңа нинди кечкенә кәгазьгә язган дип ачуланмассың бит син. Без бит, җаным, – Вернер («Җиде асылган кешеләр»дәге) әйткәнчә, каһәр тормышның һәр зарәбәсенә[2] дә күкрәк куярга хәзерләнгән кешеләр. Рәхимәнең бәхетлелеген сиңа исбат итеп торырга кирәк булмас. Аны син үзең дә аңлыйсың булыр. Хәзер мин сезгә «Фәтхулла хәзрәт»нең 3 нче җөзен җибәрәм. Укып чыккач, бер хат язарсың. Фәрханәнең минем тәүсыяны тотып-тотмаганлыгын да бер дә ялганламый язарсың, ярыймы?

«Ялт-йолт»ның әүвәлге номерлары бик сыек чыктылар. Аның өчен мин бик уңайсызландым. Ләкин чынлап язышырга бер дә вакыт арттыра алмыйм. Җәй көне дә буш вакытлар булыр дип уйлый алмыйм, чөнки укуны дәвам иттерергә уйлыйм.

«Яшьләр» тугрысында берникадәр отзывлар алдым. Яшьләр «Яшьләр»не бик, хәтта артык яраткалыйлар икән. Бу да бер нәүгы[3] партия тәгассыбы[4] бит.

«Яшьләр»нең художеств[енный] җәһәте[5] бик начар бит. Җәйгә дачага чыгарга уйлап торам.

Бу ел Казанга килеп китмисезме? Кызык булыр иде, ә!

---


[1] Катрә – тамчы.
[2] Зарәбәсенә – кагу-сугуына.
[3] Нәүгы – төре.
[4] Тәгассыб – фанатизм.
[5] Художеств[енный] җәһәте – сәнгатьлелек ягы.

Җәйгә йөз сәхифәле итеп әдәбият һәм тәнкыйть мәҗмугалары нәшер итәргә башлавымыз ихтимал. Елга өч-дүрт мәҗмуга чыга барачак.

Себердә «Ялт-йолт»ка язарлык хәбәрләр булса, минем исемгә язып җибәр, разумеется[1], иренмәсәң.

Хат яз!

Фатихың.



Фатих Әмирханның Ризван һәм Фәрханә Алушиларга язган хаты. 1909 ел, 18 ноябрь




Ризван Алуши хаты

[1] Сүз кириллицада бирелгән.

## 8. ФАТИХ ӘМИРХАННАН РИЗВАН АЛУШИГА

*1910 ел, 15 апрель, Казан*

Ризван!

Мин сезгә моннан дүрт-биш көн элек бер хат җибәргән идем. Ул хат маркалымы, юкмы? Шуны син миңа язып җибәр. Моннан башка тагы берәр хатым маркасыз барганы юкмы? Шуны да яз. Бер-ике җирдән хатлар алдым. Минем хатларым маркасыз баралар дип зарланалар. Хатларны мин малаем[1] аркылы салдыртам, ахры ул минем маркага биргән акчамны урлап кала булырга кирәк.

Фатих.

Фәрханә минем хаттан соң җыламый башладымы?

*Басмага әзерләделәр:*

***Галимҗанова Эльмера Мәхмүт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

***Хөснетдинова Гөлназ Азат кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының текстология бүлеге мөдире*

*К печати подготовили:*

***Галимзянова Эльмера Махмутовна,***
*кандидат филологических наук, ведущий научный сотрудник отдела текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*elmera.galimzyanova@mail.ru*

***Хуснутдинова Гульназ Азатовна,***
*кандидат филологических наук, заведующий отделом текстологии Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*kh-gulnaz71@mail.ru.*

[1] Фатих Әмирхан, сәламәтлеге чикләнгән булу сәбәпле, ярдәмче кеше тоткан.